“Каралды”
Методик берләшмә
җитәкчесе:
_____Җамалтдинова Л.Ш.
Беркетмә №1
“29” август, 2021 ел

“Килешенде”
Уку-укыту эшләре
буенча директор
урынбасары:
_____Шарафутдинов Р.Р.
“31“август, 2021 ел

“Расланды”
Директор:
_____Салахова Г.Р.
35 нче номерлы
боерык
“31“август, 2021 ел

***8 нче сыйныф өчен дәрестән тыш эшчәнлек программасы***

**«Илһам чишмәсе»**

**(рухи-әхлакый тәрбия бирү юнәлеше)**

**2021-2022 нче уку елы**

Төзүче: 1 категорияле туган тел һәм әдәбият (татар) укытучысы
Җамалтдинова Л.Ш.

Карлы-2021

Мәктәп укучылары арасында искиткеч сәләтле укучылар бар.Араларында,әлбәттә ,иҗади сәләте булган укучылар да шактый.Шуларны аерыр,җыйнар һәм сәләтләрен үстерү максатыннан,мәктәбебездә дәрестән тыш эшчәнлек оештырыла. Бу эшчәнлек файдалы һәм нәтиҗәле.Укучыларыбыз иҗаты районыбызның "Байрак", республикабызның"Сабантуй","Көмеш кыңгырау","Мәгърифәт"газеталары,"Салават күпере","Ялкын" журналы битләрендә даими басылып тора.Иҗади бәйгеләрдә катнашып,призлы урыннарга лаек булган укучыларыбыз шактый.

Соңгы елларда дәрестән тыш эшчәнлекне киңрәк җәелдерелеп,укучыларның актерлык сәләтен ачуда да зур эш алып барыла башлады.Укучылар сәхнә серләренә төшенеп,үзләренең осталыкларын күрсәтәләр."Ният"бәйгесендә исә "Иң яхшы хатын-кыз "роле,нәфис сүз "номинациясендә катнашып,призлы урыннар яулыйлар.Балалар үз иҗат җимешләре белән район күләмендә үткәрелә торган "Сәләтле бала"бәйгесендә дә бик теләп катнашалар.

Укучылар дәрестән тыш оештырылган чараларда теләп,яратып йөриләр

"Илһам чишмәсе" тармагы укучыларны халкыбызның рухи-әхлакый идеалларына китерергә, аларда югары сөйләм культурасы формалаштырырга,иҗади сәләтен үстерүгә,мөстәкыйль уйларга һәм эшләргә омтылышын канәгатьләндерү юнәлешендә эш алып бара,танып-белү эшчәнлеге аралашу формасында оештырыла.Укучылар газета-журналлар басу технологиясе,газета әсәрләре иҗат итүнең баскычлары(тема табу,фактлар туплау,әңгәмә үткәрү,текст төзү,ритм,рифма һ.б)журналистика жанрлары турында мәгълүмат алалар.Үзләре газета-журналлар өчен шигырьләр ,хикәяләр ,мәкаләләр иҗат итәләр,үзләре язган шигырьләрне сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнәләр."Илһам чишмәсе"дигән газета чыгаралар."Илһам чишмәсе"иҗатчылар эшчәнлеген шул газета битләрендә яктыртып бара.

**Дәрестән тыш эшчәнлекнең максаты:**

-сүзнең матурлыгын ,туган телнең кеше тормышындагы алыштыргысыз ролен укучының аңына сеңдерү аша аларда әхлак тәрбияләү;

-туган як матурлыгын күрергә,аны сакларга өйрәтү;

-укучыларны әйләнә-тирәлеккә иҗади карарга өйрәтү,аларның иҗади фикерләү сәләтен үстерү;

- укучыларны әдәби телдә матур сөйли ,сәхнәдә үз-үзләрен тото белергә өйрәтү.

**Дәрестән тыш эшчәнлекнең бурычлары:**

-укучыларны иҗади дәртләндерү,аларның йөрәгендә иҗат чишмәсен уяту;

-көндәлек матбугат белән танышып баруга күнектерү;

-мәктәптә,районда,сыйныфта булган яңалыклар,истәлекле вакыйгаларны өйрәнеп,вакытлы матбугат жанрының берсендә хәбәрләр язарга өйрәтү;

-уңышлы дип табылган әсәрләрне республикада чыгып килә торган газета –журналга тәкъди итү;

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

- халык акылы , тормыш яме, яшәү көче чыганагы булган халык авыз иҗаты турында мәгълүматлы булу

- әсәрләрнең жанрын аера белү.

- әкият, легендаларның эчтәлеген сөйли белү.

- халык җырларын, биюләре элементларын белү.

- сөйләмдә мәкаль-әйтемнәр кулланырга өйрәнү.

- халык уеннарын өйрәнү.

- татар телендә кечкенә әсәрләрне сәхнәләштерү.

- төркемдә партнер белән эшли белү.

- баланың үз эшенә билге куя белүе .

**Укытуның шәхси нәтиҗәләре**

Гомуми белем бирү мәктәбен тәгәлләгәндә, укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге **шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана**:

- шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
- әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
- текстлардагы төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
- «гаилә», «туган ил», «мәрхәмәтлелек» төшенчәләрен кабул итү, «башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык», «кеше кадерен белү» кебек хисләр формалашу.

**Укытуның метапредмет нәтиҗәләре**

Төп белем бирү баскычында телгә өйрәтү, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыруга хезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар, презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәнә; укучыларда, компьютер яисә ИКТ ның башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алу күнекмәләре формалаша.

***Танып белү нәтиҗәләре:***

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
- объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
- төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү.

***Регулятив нәтиҗәләр*:**

- уку хезмәтендә үзенә максат куя, бурычларны билгели белү;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;

***Коммуникатив* нәтиҗәләр:**

- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
- аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисләлек, эмпатия хисләре);
- парларда һәм күмәк эшли белү;
- мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
- әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

- **Программаны тормышка ашыру шартлары һәм көтелгән уңышлар:**
- Программа җитәкчедән фәнни-педагогик әзерлеккә ия булуны таләп итә.Укытучының филология,тарих,журналистика,рәсем сәнгате буенча билгеле бер күләмдә белеме ,сәләте,күнекмәләре булырга тиеш.Һәрдаим эзләнгәндә,бай

материал туплап,белгечләр белән киңәшләшеп,аларны эшчәнлеккә җәлеп иткәндә ,яхшы нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин.

- Белем бирү программасы шактый катлаулы,шуңа күрә дәрестән тыш эшчәнлеккә йөрүче балаларның занятиеләргә системалы йөрүе кирәк.Эш тәҗрибәсе шуны күрсәтә:теритик материал һәм дәрестә гамәли эш белән ныгытылырга тиеш.Укучылар үз көчләре белән нәрсәдер иҗат итсәләр,язсалар,кызыксыну арта.Шуны истә тотып программада гамәли дәресләр өстенлек итә.
- Дәрестән тыш эшчәнлек өчен һәр укучыда карандаш,ручка,блокнот кәгазьләр,флешкалар булдырырга кирәк.Куркынычсызлык кагыйдәләре һәрдаим искә төшерелеп торсын,ул инструктаж дәфтәренә теркәлсен.
- Күрсәтмә материалны мультимедиа чаралары аша файдалану уңышлы.Ул дәреснең эффектлыгын арттыра,педагогнын эшен бермә-бер җиңеләйтә.вакытка экономия ясый.Әлеге программаны тулысынча тормышка ашыру өчен берләшмә утырышлары үткәрелә торган кабинетка интернет челтәре тоташкан компьютер,ноутбук,цифрлы фотоаппарат,төсле принтер кирәк булачак.Курс буенча методик эшкәртмәләрнең аз булуы эштә күп кыенлыклар тудыра.Программа авторы бу юнәлештә туктаусыз эзләнү алып бара.
- Программа материалын уңышлы үзләштергән укучы түбәндәге белем-күнекмәләргә ия булырга тиеш:
- -мәктәптә яки сыйныфта үткәрелгән чара турында хәбәр яза;
- -ритм һәм рифманы иҗат эшендә дөрес итеп куллана;
- -журналистикадага жанр төрләрен һәм үзенчәлекләрен дөрес файдалана ала;
- -һәр эшендә пөхтәлеккә,язмаларының дөреслегенә ирешергә;
- -журналистика барлыкка килү, үсеш тарихыннан хәбәрдар, шартларда журналистикадагы үсеш тенденцияләре белән килгән яңалыкларны вакытында белеп бара;
- -сузләрдән образ тудыра, художестволы чаралар ярдәмендә
- -үзе иҗат иткән шигырьне сәнгатьле итеп сөйли;
- -авторлык хокуклары турындагы законның төп положенияләрен белә һәм аны үти;
- -үз милләтенең культурасы, сәнгате һәм әдәбияты белән горурлану хисләре кичерә;
- -хәзерге татар әдәби телендәаралаша һәм сәхнәдән торып сөйли белә;
- -татар драмматургиясенең күренекле вәкилләре һәм аларның иҗаты турында фикер йөртә ала;
- -сәхнәдә уйнала торган чараларны оештыра белә;
- -иҗади бәйгеләрдә катнаша

**Әдәбият исемлеге**

1. Гарифуллин В.Г.”Үткен каләм, үткен күз”. Казан: Тат. Китап нәшр.,1995 – 165 б.

2. Гарифуллин В.Г. “Журналистның иҗади эшчәнлеге нигезләре” 2004 – 205 б.

3. Курбатов Х.Р. “Сүз сәнгате. Татар теленең лингвистик стилистик һәм политикасы”. Казан: “Мәгариф” нәшр., 2002 – 200 б.

4. Хәйруллина А.Х. Тел күрке – суз(матур сөйләргә өйрән)./А.Х.Хәйруллина.-Казан: Тат. Кит. Нәшр., 1978-113б.

5 .Кружок театра кукол. Методическое пособие./Под ред. Л.Г. М: «Просвещение», 1967-103 с.

6. В школьном театре: Инсценировка произведений русских писателей классиков, песни и романсы на слова поэтов 19 века. –М: «литература», 1971-513 с.

7. Низамов И.М. Матбугатның тәэсирле сузе./И.М.Низамов. Тат.кит.нәшр., 1988-144 б.

8. “Сабантуй”, “Көмеш кыңгырау”, “Йолдыз” газеталары, “Идел”, “Ялкын” журналлар

Укыту курсының эчтәлеге

“Илһам чишмәсе” (35 сәг) 8 нче сыйныф

| № | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1-2 | Оештыру эшләре.Укучыларны дәрестән тыш эшчәнлеккә туплау,максат һәм бурычлар белән таныштыру | 2 |
| 3-4 | Газета ничек ясала?<br>Журнал ясау үзенчәлеге | 2 |
| 5-6 | Хәбәрчегә хас сыйфатлар.<br>Районыбызның даны ул Илсөяр Гаязетдинова-район газетасы хезмәткәре | 2 |
| 7-8 | Минем яраткан газетам.<br>Минем яраткан журналым | 2 |
| 9-10 | “Байрак”район газетасына экскурсия | 2 |
| 11-12 | Газета алдаганны яратмый.Газеталарга күзәтүләр | 2 |
| 13-14 | Газета-журналлардагы фоторәсемнәр.Рәсем ясау,рәсемгә исем куярга өйрәтү | 2 |
| 15- | Илсөяр Гаязетдинова-район газетасы хезмәткәре белән | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| 16 | очрашу.Очрашу истәлекләре язу. | |
| | Журналистикада жанр төрләре | |
| 17-18 | Хәбәри жанрлар.Хәбәр язарга өйрәнәбез.Мәктәптә булган вакыйга яки факт турында язу | 2 |
| 19-20 | Динә апа Камалетдинова белән очрашу. | 2 |
| 21 | Репортаж-күзәтүче жанр.Очрашулар,бәйрәмнәрдән репортажлар язу | 1 |
| 22 | Репортаж-күзәтүче жанр.Очрашулар,бәйрәмнәрдән репортажлар язу | 1 |
| 23-26 | Аналитик жанрлар<br>Корреспонденция-җәмәгатьчелек игътибарын проблемага юнәлтә.<br>Мәкалә һәм аның төрләре:үтенеч,сорау,информация,бәяләмә,рәхмәт | 4 |
| 27-28 | Газета-журналларда басылган әхлак темасын чагылдырган шигырьләргә күзәтү | 2 |
| 29-30 | Авыл китапханәсендә кунакта | 2 |
| 31-32 | “Илһам чишмәсе”газетасын чыгару | 2 |
| 33-34 | Уеннар”башын башлыйм,син тәмамла” | 2 |
| 35 | Еллык нәтиҗә | 1 |

**Тематик план**

| № | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Оештыру эшләре.Укучыларны дәрестән тыш эшчәнлеккә туплау,максат һәм бурычлар белән таныштыру | 1 |
| 2 | Оештыру эшләре.Укучыларны дәрестән тыш эшчәнлеккә туплау,максат һәм бурычлар белән таныштыру | 1 |
| 3 | Газета ничек ясала? | 1 |
| 4 | Журнал ясау үзенчәлеге | 1 |
| 5 | Хәбәрчегә хас сыйфатлар. | 1 |
| 6 | Районыбызның даны ул- Илсөяр Гаязетдинова-район газетасы хезмәткәре | 1 |
| 7 | Минем яраткан газетам. | 1 |
| 8 | Минем яраткан журналым | 1 |
| 9 | "Байрак"район газетасына экскурсия | 1 |
| 10 | "Байрак"район газетасына экскурсия | 1 |
| 11 | Газета алдаганны яратмый.Газеталарга күзәтүләр | 1 |
| 12 | Газета алдаганны яратмый.Газеталарга күзәтүләр | 1 |
| 13 | Газета-журналлардагы фоторәсемнәр. | 1 |
| 14 | Рәсем ясау,рәсемгә исем куярга өйрәтү | 1 |
| 15 | Илсөяр Гаязетдинова-район газетасы хезмәткәре белән очрашу. | 1 |
| 16 | Очрашу истәлекләре язу. | 1 |
| 17 | Журналистикада жанр төрләре | 1 |
| 18 | Хәбәри жанрлар. | 1 |
| 19 | Хәбәр язарга өйрәнәбез.Мәктәптә булган вакыйга яки факт турында язу | 1 |
| 20 | Динә апа Камалетдинова белән очрашу. | 1 |
| 21 | Репортаж-күзәтүче жанр.Очрашулар,бәйрәмнәрдән репортажлар язу | 1 |
| 22 | Репортаж-күзәтүче жанр.Очрашулар,бәйрәмнәрдән репортажлар язу | 1 |
| 23 | Аналитик жанрлар | 1 |
| 24 | Корреспонденция-җәмәгатьчелек игътибарын проблемага юнәлтә. | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | проблемага юнәлтә.<br>Корреспонденция-җәмәгатьчелек игътибарын проблемага юнәлтә. | |
| 26 | Корреспонденция-җәмәгатьчелек игътибарын проблемага юнәлтә. | 1 |
| 27 | Корреспонденция-җәмәгатьчелек игътибарын проблемага юнәлтә. | 1 |
| 28 | Мәкалә һәм аның төрләре:үтенеч,сорау,информация,бәяләмә,рәхмәт | 1 |
| 29 | Газета-журналларда басылган әхлак темасын чагылдырган шигырьләргә күзәтү | 1 |
| 30 | Газета-журналларда басылган әхлак темасын чагылдырган шигырьләргә күзәтү | 1 |
| 31 | Авыл китапханәсендә кунакта | 1 |
| 32 | "Илһам чишмәсе"газетасын чыгару | 1 |
| 33 | Уеннар"башын башлыйм,син тәмамла" | 1 |
| 34 | Уеннар"башын башлыйм,син тәмамла" | 1 |
| 35 | Еллык нәтиҗә | 1 |